Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## "Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында" Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 10 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 28 маенда
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында" 1999 елның 17 ноябрендәге 2440 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 1(1); 2001, № 3; 2002, № 12 (II өлеш); 2004, № 3 (IV өлеш); 2005, № 4 (I өлеш), № 7 – 8; 2006, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 6 март) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяда:

а) 4 пунктта "аппараты хезмәткәрләрен эшкә кабул итү һәм эштән азат итү" сүзләрен "аппаратын кадрлар белән тәэмин итү" сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ пункт өстәргә:

"$4^1$. Җәмәгать судьясы аппаратының кадрлар составын туплау дәүләт граждан хезмәте турындагы законнарда каралган тәртиптә конкурс нигезендә башкарыла.";

2) 10 статьяга түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

"$3^1$. Җәмәгать судьяларының мәгълүмат ресурсларын берләштерелгән белешмәләр базаларына һәм белешмәләр банкларына кертү чаралары, мәгълүмат системаларының эшләвенә, бердәй принциплар һәм гомуми кагыйдәләр нигезендә эшли торган мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдалануга карата

бердәй техник таләпләрне урнаштыру федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 11 июне
№ 35-ТРЗ